СОВЕТ НИЖНЕШАНДЕРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1, с. Зюри,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422153

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТҮБӘН ШҮЛӘҢГЕР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 1 нче йорт, Җөри авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422153

тел.(факс): (85563) 3-87-31; e-mail: Nsnd.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар
«15» апрель, 2024 ел

Решение
№ 4-33

**Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрен хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлеше, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Советы КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Түбән Шүләңгер авыл җирлеге Башкарма комитетының түбәндәге вәкаләтләрен тапшыру турындагы мәсьәләне карарга тәкъдим итәргә:

җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт булдыру һәм аның эшчәнлеге тәртибен раслау;

гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү.

2. Мамадыш муниципаль районы Советы тарафыннан әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән тәкъдим кабул ителгән очракта, Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башкарма комитетына:

Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты белән әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән вәкаләтләрне тапшыру турында килешү төзергә;

Әлеге карарны гамәлгә ашыруны тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге советы карары проектын 2024 елга һәм 2025 һәм 2026 еллар план чорына Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү хакында бюджет законнары нигезендә эшләргә һәм карауга тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы рәсми сайтында, “Интернет” мәгълүмати- коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләр Порталында http://mamadysh.tatarstan.ru/ веб- адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) игълан итәргә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районының Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы Е.М.Михайловага йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Түбән Шүләңгер авыл җирлеге башлыгы,
авыл җирлеге Советы рәисе /Е.М.Михайлова/